## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы
Бәзәкә авыл җирлегенең Сәйтәк торак пунктында граждannar җыены нәтиҗәләре турында

2023 елның 25 ноябрендәге 5 номерлы
гражданнар җыены карарына үзгәрешләр
кертү турында

22.06.2024 ел № 13

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлеге башлыгының 2024 елның 13 июнендәге 7 номерлы «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегенең Сәйтәк торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында» карары белән 2023 елның 25 ноябрендәге 5,6 номерлы гражданнар җыеннары карары буенча җыелган гражданнардан үзара салым акчаларын файдалану мәсьәләсе буенча 2024 елның 22 июнендә узган Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авылы җирлегенең Сәйтәк торак пунктында гражданнар җыенының нәтиҗәләре белән “Сез 2023 елның 24 ноябрендәге 1,2 номерлы гражданнар җыены карарлары нигезендә җыелган үзара салым акчаларының бер өлешен түбәндәгечә кулланырга ризамы?” дигән сорау буенча йомгаклау беркетмәсе төзелде

– Торак пункт территориясен төзекләндерү (МТЗ 82.1 тракторын сатып алуны финанслау).
- Торак пункт территориясен төзекләндерү (трактор өчен асмалы җиһазлар ( отвал, косилка) сатып алу»"
Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмәгә ярашлы: сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 117 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны - 80 кеше.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«риза» - гражданнар җыенының 80 катнашучысы тавыш бирә;
«каршы» - җыенның 0 катнашучысы тавыш бирә.
Бу нигездә, гражданнар җыенын:

1. Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегенең Сәйтәк торак пунктында гражданнар җыены узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләре гамәлдә дип танырга
2. “Сез 2023 елның 25 ноябрендәге 5,6 номерлы гражданнар җыены карарлары нигезендә җыелган үзара салым акчаларының бер өлешен түбәндәгечә кулланырга ризамы?” дигән сорау буенча карар кабул ителгән дип санарга.

– Торак пункт территориясен төзекләндерү (МТЗ 82.1 тракторын сатып алуны финанслау).
- Торак пункт территориясен төзекләндерү (трактор өчен асмалы җиһазлар ( отвал, косилка) сатып алу»"

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, карар кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Татарстан Республикасы

хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында. www mendsleevsk.tatarstan.ru “Бәзәкә авыл җирлеге” бүлегендә бастырып чыгарырга

4. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлеге башлыгына әлеге карарны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Менделеевск муниципаль районы
Бәзәкә авыл җирлеге башлыгы _______________ И.И. Кәшәфетдинов